**Контрольно - измерительные материалы**
**для проведения промежуточной аттестации**
**(тестирование)**
**по литературному чтению (татарскому)**
**(для изучающих татарский язык как родной)**
**3 класс**

## Спецификация

**Назначение проверочной работы** - оценить уровень сформированности предметных результатов по итогам усвоения программы по учебному предмету «Литературное чтение (на татарском языке)» обучающимися 3 класса.

**Структура КИМ**

Тест состоит из 2 частей: часть 1 включает 10 заданий с выбором ответа либо с записыванием краткого ответа; часть 2 состоит из заданий работы с текстом.

Время выполнения работы 45 минут.

## Кодификатор контрольно - измерительного материала

<table>
<tr><th>№ задания</th><th>Проверяемые элементы содержания</th><th>Планируемые результаты</th><th>Максим. балл</th></tr>
<tr><td>Тест<br>А1</td><td>Знание татарских поэтов</td><td rowspan="8">предметные: проверить полученные знания и умения<br><br>коммуникативные: умение размышлять и формулировать<br><br>регулятивные: умение достигать поставленной цели<br><br>познавательные: использование приобретенных знаний</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А2</td><td>Умение соотносить автора и его произведения</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А3</td><td>Знание содержания произведения</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А4</td><td>Умение определять жанры УНТ</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А5</td><td>Знание литературных тропов</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А6</td><td>Умение соотносить автора и его произведения</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А7</td><td>Знание содержания произведения</td><td>1</td></tr>
<tr><td>А8</td><td>Умение соотносить содержание произведения и народной пословицы</td><td>1</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| А 9 | Знание содержания произведения | **личностные:** понимание своих возможностей | 1 |
| А10 | Знание произведений живописи татарских художников | | 1 |
| Текст, задания В11 | Умение работать с текстом, выбирать конкретную информацию из текста | | 2 |
| В12 | Умение рассуждать и выражать письменно свои мысли | | 2 |
| В13 | Умение работать с текстом, выбирать конкретную информацию из текста | | 2 |
| В14 | Знание содержания текста, умение составлять план текста | | 2 |

**Критерии оценивания:**

| Балл | 16-18 балл | 13-15 балл | 9 -12 балл | 0 - 8 балл |
|---|---|---|---|---|
| % | 92-100 % | 75-91% | 50 -74% | Менее 50% |
| Билге | “5” | “4” | “3” | “2” |

## I нче вариант

**1 нче өлеше (А)**

**А1.** Габдулла Тукай кем ул?

а) рәссам;
б) шагыйрь;
с) язучы.

**А2**. Бу юллар кайсы әсәрдән?

- *Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:*
*Картаеп каткач буыннар – эш белү уңайсыз ул!*

а) Мәҗит Гафури «Китап һәм балалар»;
б) Газинур Морат «Туган тел»;
с) Габдулла Тукай «Кызыклы шәкерт».

**А3**. Р. Гыйззәтуллинның «Кечкенә Ринат» хикәясендә Ринат кая еш йөри?

а) китапханәгә;
б) ашханәгә;
с) шифаханәгә.

**А4**.*Табышмак, мәсәл, мәкаль, мәзәк, тизәйткеч, санамышлар* икенче төрле ничек атала?

а) халык әсәрләре;
б) халык авыз иҗаты әсәрләре;
с) кызыклы әсәрләр.

**А5**. Җансыз предметны, күренешне җанландырып күрсәтү ничек атала?

а) сынландыру;
б) чагыштыру;
с) рифма.

**А6**. А. Алиш язган әкиятләрне билгеләгез.

а) «Су анасы», «Шүрәле»;
б) « Гөлчәчәк», «Себерке әкияте»;
с) «Чукмар белән Тукмар», «Утлы йомырка».

**А7**. «Кояштагы тап» әкиятендә кояшта ни өчен тап барлыкка килә?

а) малай әнисенә ялганлый;
б) кыз әнисенә булышмый;
с) абыйсы энесенә булыша.

**А8**. « Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне» мәкале кайсы әкияткә туры килә?

а) «Су анасы»;

б) «Тату туганнар»;

с) «Чукмар белән Тукмар».

**А9**. « Караурманга бара Мөбәрәк» әкиятендә малай кемгә булыша?

а) апасына;

б) әнисенә;

с) дустына.

**А10**. Л. Ә. Фәттаховның «Әни күрмәгәндә» картинасында нинди ел вакыты сурәтләнгән?

а) яз;

б) кыш;

с) җәй.

**2 нче өлеше (В)**

**Ак песи**

Идел-елга буенда, ямьле яр тугаенда зәңгәр тәрәзәле, зәңгәр болдырлы, зәңгәр капкалы бик матур бер йорт утырган. Шушы ак йортта бик тә матур, кеп-кечкенә ике песи баласы торган. Аларның берсе ап-ак мамыктай күперенке тунлы, үзе күк күзле, үзе бик тә үзсүзле булган, икенчесе аклы-сорылы, үзе дә сары, әмма үзе бик тә акыллы, тыйнак һәм сүз тыңлаучан икән.

Бервакытны бу песиләр икесе бергә зәңгәр болдырның зәңгәр баскычында зәңгәр чынаяктан сөт эчеп торганда, баскыч төбендә кечкенә генә кап-кара бер көчекне күреп алганнар. Бу көчек бик тә нәүмизләнеп, боегып кына песи балаларының сөтләренә карап тора, ә үзе, сөт эчәсе килүен белгертергә теләгәндәй, еш-еш койрыгын болгый икән.

Ак песи баласы, көчекне күрүгә, ап-ак сыртын кабартып җибәргән, тешләрен ыржайткан да күк күзләрендә зәңгәр очкыннар уйнатып:

- Кит моннан! – дип ысылдаган. Соры песи аптырап ак песигә караган.

- Бу нишләвең, Аппагым? Күрмисеңмени, безнең кунагыбызның да сөт эчәсе килгән бит! – дигән ул, иреннәрен ялап торган кара көчеккә күрсәтеп.

- Килсә соң! Анда минем ни эшем бар! Безнең зәңгәр баскычтан хәзер үк китсен! Югыйсә менә шушы тырнакларым белән күзләрен тырнап бетерәм мин аның! – дигән ак песи һәм, кечкенә генә йомшак тәпиен күтәреп, үзенең бик тә очлы, бик тә үткен тырнакларын күрсәткән.

- Алай ярамый, сеңелем! Бәлки аның сыеныр урыны юктыр, хәлен белергә, ярдәм итәргә кирәк үзенә! – дигән соры песи.
- Сыеныр урыны, имеш! Шул гына җитмәгән иде! Сыеныр урынсыз көчек була димени! Минем андыйларны күргәнем дә юк, күрәсем дә килми! – дигән ак песи бик эре генә.

Соры песи туганының бу сүзләре өчен бик тә оялган һәм зәңгәр баскычтан сикереп төшкән дә кара көчекне әйдәп, үзе белән сөтле чынаяк янына алып килгән.
- Курыкма син аннан, курыкма, эч сөтне, эч! Үсмәгән әле ул, дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми, - дигән соры песи һәм, тынычландырырга тырышып, кара көчекнең борын очын ялап алган. Шуннан кара көчек курка-курка гына булса да сөтне эчә башлаган.

Резедә Вәлиева

**В11.** Көчекне күргәннән соң ак песинең үз-үзен тоту эзлеклелеген билгелә.
*Ысылдаган, тешләрен ыржайткан, күк күзләрендә зәңгәр очкыннар уйнаткан, ап-ак сыртын кабартып җибәргән.*

1. ________________________________, 2.______________________________,
3.________________________________, 4.__________________________________.

**В12.** *Бәлки аның сыеныр урыны юктыр, хәлен белергә, ярдәм итәргә кирәк үзенә! – дигән соры песи.*
Бу җөмләдәге “*сыеныр урыны юктыр*” дигәнне ничек аңлыйсыз?
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

**В13.** Төшеп калган сыйфатларны теисттан эзләп языгыз.
Аларның берсе ап-ак___________________тунлы, үзе____________күзле, үзе бик тә ______________ булган, икенчесе___________________________, үзе дә_____________, әмма үзе бик тә акыллы, тыйнак һәм________________________икән.

**В14.** Хикәянең планын дөрес итеп төзеп языгыз (җөмләләр саннарын).

1. Көчек килде. 2. Песиләр сөт эчә. 3.Ак песи ачуланды. 4. Бик матур бер йорт. 5. Соры песи ярдәмгә килде. 6. Дуслык кадере.
__________________________________________________________________________

**Дөрес җаваплар**

| № | җавап |
|---|---|
| **А1** | **б** |
| **А2** | **в** |
| **А3** | **а** |
| **А4** | **б** |
| **А5** | **а** |
| **А6** | **с** |
| **А7** | **а** |
| **А8** | **б** |
| **А9** | **а** |
| **А10** | **а** |